**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БӨГЕЛМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ "ВОСТОЧНЫЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ" МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**V ЧАКЫРЫЛЫШ**

**ДҮРТЕНЧЕ СЕССИЯ**
**3 нче КАРАР**

Восточный б. 2025 елның 12 декабре

**«Татарстан Республикасы**
**Бөгелмә муниципаль районы**
**Восточный авыл җирлеге**
**Советы Регламенты турында»**
**Татарстан Республикасы**
**Бөгелмә муниципаль районы**
**Восточный авыл җирлеге Советының**
**2014 елның 11 августындагы**
**447 номерлы карарына**
**үзгәрешләр кертү хакында**

«Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында "26.01.2023 ел, № 1-ТРЗ ТР Законы үз көченә керүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасының «Восточный авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, «Восточный авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы карар кабул итте:

1. «Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Восточный авыл җирлеге Советы Регламенты турында» Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Восточный авыл җирлеге Советының 2014 елның 11 августындагы 447 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 29 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Җирлек башлыгы яңа сайланган җирлек советының беренче сессиясендә җирлек Советы депутатлары арасыннан яшерен яисә ачык тавыш бирү юлы белән җирлек Советы вәкаләтләре чорына сайлана. Җирлек башлыгын сайлау җирлек Советы депутатлары тарафыннан күрсәтелә торган кандидатлар арасыннан, шул исәптән гражданнар, иҗтимагый берләшмәләр, Татарстан Республикасы Рәисе тәкъдимнәре нигезендә гамәлгә ашырыла.»

2. Әлеге карар Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Восточный авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставында билгеләнгән тәртиптә үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

«Восточный авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге
Башлыгы В.Ю. Тимофеев